КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1069

Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының милли рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасында инвестицион климат торышын яхшырту чараларын тормышка ашыру турында

Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының милли рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасының инвестицион климатын яхшырту максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Урта Идел төбәкара дәүләт автомобиль юллары күзәтчелеге идарәсе, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә, 2019 елның 20 декабренә кадәр Татарстан Республикасында инвестицион климат торышын яхшырту буенча, шул исәптән дәүләт хезмәтләре, муниципаль һәм башка хезмәтләр күрсәтүне оптимальләштерүнең күреләчә торган чаралары буенча

үткәрелә торган һәм аны тормышка ашыру кысаларында эшмәкәрлек берләшмәсенә тиешле мәгълүмат бирү тәэмин ителә торган эшне массакүләм мәгълүмат чараларында даими яктырту медиапланын әзерләргә.

2. Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына сораштырулар, анкета алу яки кире элемтә алуның башка уңайлы формалары ярдәмендә дәүләт хезмәтләре, муниципаль һәм башка хезмәтләр күрсәткәндә җитешсезлекләрне ачыклау һәм бетерү максатларында юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр белән үзара хезмәттәшлекне даими нигездә оештырырга, шулай ук «Сетевая компания» ачык акционерлар җәмгыятенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Транспорт өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Урта Идел төбәкара дәүләт автомобиль юллары күзәтчелеге идарәсенә, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына аны даими нигездә оештыруны тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына 2019 елның 20 декабренә кадәр теркәү (салым) органы һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре арасында электрон хезмәттәшлекне тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

4. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, 2019 елның 20 декабренә кадәр дәүләт хезмәтләрен электрон рәвештә күрсәтүнең тулы циклын (соратудан һәм гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүне үтәү барышы турында хәбәр итүдән алып хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә биргәнгә кадәр) тәэмин итү максатларында турыдан-туры үзара хезмәттәшлек итү веб-сервисларын булдыруны һәм аларның эшләвен тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, 2019 елның 30 декабренә кадәр Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә төзелешкә рөхсәт бирү буенча дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен электрон төргә күчерүне тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасының Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән берлектә, 2019 елның 25 декабренә кадәр түбәндәгеләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карап тикшерүгә кертергә:

6.1. Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының милли рейтингы күрсәткечләрен формалаштыру методологиясе нигезендә төзелешкә рөхсәтләр бирү буенча түбәндәге процедураларны үтү вакытларын һәм механизмнарын оптимальләштерү мөмкинлеге турында тәкъдимнәр:

җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын алу;

капиталь төзелеш объектларының техник шартларын алу һәм аларны инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) шартнамәләрен төзү;

капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт алу;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге үзенчәлекләренә бәйле булган өстәмә рөхсәтләр алу.

6.2. Территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру документларын «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәреш кертү турында» 2017 елның 31 декабрендәге 507-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү эшләрен этаплап финанслау тәкъдимнәре (аны исәпләп чыгарулар).

7. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына «Татарстан Республикасының Киңлек мәгълүматлары фонды» дәүләт бюджет учреждениесе һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре белән берлектә, 2020 елның 1 августына кадәр җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә (Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә расланган) мәгълүматлары булган торак пунктлар чикләрен һәм территориаль зоналар чикләрен Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына исәпкә куюны тәэмин итәргә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин